РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«9» декабрь 2020 ел г. Альметьевск № 1805

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 29 маендагы 1050 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет даирәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 29 маендагы 1050 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 24 июнендәге 1182 номерлы, 2020 елның 16 июлендәге 959 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 3 пунктындагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазифасы | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе (бүлеге) булып торучы үзәкләштерелгән |

Зак. № 3063

| | | бухгалтерия өчен |
|---|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 28 634 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 26 986 | |
| Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 26 986 |
| Бүлек җитәкчесе | 21 115 | 21 115 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 17 304 | 17 304 |
| Әйдәп баручы белгеч (эшчәнлек юнәлеше) | 17 304 | 17 304 |
| Бухгалтер | 15 759 | 15 759 |
| Белгеч (эшчәнлек юнәлеше) | 15 759 | 15 759 |

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ